СОВЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29.04.2021 г.Мензелинск № 7

Торак урыны мәйданының исәп-хисап нормасы һәм социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны мәйданын бирү нормасы турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 50, 58 статьяларын гамәлгә ашыру, дәүләт торак программаларын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында торак урыны мәйданының гомуми мәйданы белән тәэмин итү дәрәҗәсе гаиләнең бер әгъзасына 18 кв.метрдан да ким булмаган гомуми мәйданы күләмендә билгеләнә торган торак урыны мәйданының исәп нормасын билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында бер гражданинга торакның гомуми мәйданын 18 кв.метр күләмендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннары белән тәэмин ителешнең ирешелгән дәрәҗәсеннән чыгып, социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны мәйданын бирү нормасын билгеләргә.
3. Торак урынының гомуми мәйданын бирү нормасын арттыру Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда рөхсәт ителә.
4. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Советының «Социаль наем һәм Дәүләт торак программалары буенча гражданнарга торак бирү һәм исәпкә куелганда торак мәйданы нормалары турында» 2006 елның 14 июлендәге 3 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны мәгариф, мәдәният, сәламәтлек саклау, яшьләр эшләре, спорт һәм социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Совет Рәисе А. Ф. Сәлахов